2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авылы җирлеге Тайсуган авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

16 ноябрь 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлегенең Тайсуган авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Тайсуган авыл җирлеге Тайсуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, сугышчан хәрәкәтләр барган Әфганстан Республикасында һәм башка илләрдә интернациональ бурычны үтәгән гражданнардан, шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, хатыны, балалары) тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; тротуар төзү, ремонтлау (Сәлахетдинов, Ленин, Тукай урамнарындагы тротуарларны ремонтлау).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Тайсуган авылы, Сәлахетдинов урамы, 36б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тайсуган авыл җирлеге башлыгы М.Ф. Мостафин